# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**09 ноябрь 2023 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән гражданнардан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Балан-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау, тоту (Ленин урамы буенча вак ташлар салу, тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Балан-Бүләк авылында урамнарны яктырту өчен лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү;
- һәйкәлләрне ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү ( материаллар сатып алу, буяу, агарту, килешү буенча эш өчен түләү);
- Балан-Бүләк торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү (үлән чабу буенча хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы ___________ А.М.Мөхәмәтшин